РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 5 июне г.Кукмор № 290

Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль вазыйфага яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфага яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны

_______________________________________________

*(җаваплы затның фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы)*

йөкләргә.

Район Башлыгы С.Д.Димитриев

Кукмара муниципаль районы Советының
2020 елның 5 июнендәге 290 номерлы
карарына кушымта

Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына (алга таба – муниципаль вазыйфаны биләүче зат) карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр (алга таба – керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр) биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, җаваплылык чараларын (алга таба – җаваплылык чаралары) куллану турында карар кабул итү процедурасын регламентлый.

2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $7^{3-1}$ өлеше нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган белешмәләр биргән муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) депутатны, Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасын, Кукмара муниципаль районы Советында, җирле үзидарә сайланулы органында аның вәкаләтләре вакыты тәмамланганчы вазифа биләүдән мәхрүм итеп, Кукмара муниципаль районы Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазыйфадан азат итү;

3) аның вәкаләтләре вакыты тәмамланганчы, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә Советында, сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю;

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылык чараларының берсе буларак куллану турындагы мәсьәлә Кукмара муниципаль район Советы (алга таба – Совет) тарафыннан карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $7^3$ өлешендә каралган муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президентының Советка кергән гаризасы нигез булып тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет тарафыннан  кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка, аңа карата күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр биш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә язма рәвештә җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау хакында хәбәр итә.

Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның килмәве Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.

6. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президентының гаризасы Совет утырышында Кукмара район Советының 2005 елның 10 декабрендәге 17 номерлы карары белән расланган Совет Регламентында (алга таба – Регламент) билгеләнгән тәртиптә карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда, муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка тапшырылган мәгълүматлар буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мәсьәләне караганда, депутатлар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәислек итүче депутатларга мәнфәгатьләр каршылыгының барлыкка килүе яисә барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тәкъдим итәргә бурычлы.

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу максатларында, мәнфәгатьләр конфликтын яклаучы депутат рәислек итүче тарафыннан карар кабул итүдән читләштерелә.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Әлеге карар Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Президентының аңа карата гаризасы кергән депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар гаделлек, тиңлек, пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә, кылынган коррупцион хокук бозу характерын, аның авырлыгын, хәлләрне, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче затның үз вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) үтәүнең алдагы нәтиҗәләрен, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәүләрен исәпкә алып кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен бары тик бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупцион хокук бозу турында, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләренә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга карата шикаять бирү хокукына күрсәтмә булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын куллануудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын куллануудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфа биләүче затка имза куйдырып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаган яисә күрсәтелгән зат имза куеп карар кабул итүдән баш тарткан очракта, Кукмара шәһәр Советының баш белгече югарыда күрсәтелгән затның җаваплылык чараларын куллану турында карар белән танышудан баш тартуы яки аңа мондый карар турында хәбәр итү мөмкинлеге булмау турында акт төзи.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын куллануудан баш тарту турындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.